БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2020 ел № 31

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2021 елга муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2021 елга муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.

2. Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына, Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.С.Галимуллинга 2021 елга хосусыйлаштыруның фараз планына кертелгән күчемсез милек объектларының исемлеген халык, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм барлык кызыксынган затларга җиткерергә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин

16 декабрь 2020 елгы №31
Татарстан Республикасы
Балтач район Советы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2021 елга муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

| № | Объектның характеристикасы | Объектның адресы | Мәйдан, кв.м. | Объектның билгеләнеше | Хосусыйлаш-тыруның фаразланган сроклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Балалар бакчасы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бинасы, кадастр номеры 16:12:060401:311, мәйданы 186,3 кв.м 1990 елда төзелгән, якын-тирә җир кишәрлеге кадастр номеры 16:12:060401:85 кадастр номеры белән, мәйданы 3288,11 кв. м булган җир кишәрлеге белән, «торак пунктлар җирләре» категориясе, балалар бакчасы бинасы өчен рөхсәт ителгән җир төре» | Балтач муниципаль районы, Түбән Кнә авылы, Школьная урамы, 9 нчы йорт | 186,3 | Балалар бакчасы бинасы | 2021елның II яртыеллыгы |
| 2 | Авыл клубы бинасы, кадастр номеры 16:12:080301:247, мәйданы 186,3 кв.м 1966 елда төзелгән, якын-тирә җир кишәрлеге кадастр номеры 16:12:080301:65, мәйданы 483 кв. м., «торак пункт җирләре" категориясе», рөхсәт ителгән куллану төре «музыкаль, сәнгать хореография мәктәпләре, клуб учреждениеләре җитәкчеләре китапханә хезмәткәрләре» | Балтач муниципаль районы, Чапшар авылы, Х.Туфан урамы, 20 /1 нче йорт | 186,3 | Авыл клубы бинасы | 2021елның II яртыеллыгы |
| 3 | Мәктәп интернат бинасы, кадастр номеры 16:12:150108:253, мәйданы 215,4 кв.м., 1968 елда төзелгән, якын-тирә җир кишәрлеге кадастр номеры 16:12:150108:14, мәйданы 823,99 кв.м., «торак пунктлар | Балтач муниципаль районы, Чепья авылы, Школьная урамы, 1 нче йорт | 215,4 | Мәктәп интернаты | 2021елның II яртыеллыгы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | җирләре» категориясе, рөхсәт ителгән куллану төре «интернат бинасы астында» | | | | |
| 4 | Торак булмаган бина, кадастр номеры 16:12:010116:103, мәйданы 197,6 кв.м., 1899 елда төзелгән, якын-тирә җир кишәрлеге кадастр номеры 16:12:010116:11, мәйданы 473,83 кв.м., «торак пунктлар җирләре» | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Балтач шәһәр тибындагы поселок, Ленин урамы, 28 нче йорт | 197,6 | Торак булмаган бина | 2021 елның II яртыеллыгы |
| 5 | Житештерү остаханәсе бинасы, кадастр номеры 16:12:060101:300, мәйданы 110,3 кв.м., 1983 елда төзелгән, якын-тирә җир кишәрлеге кадастр номеры 16:12:060101:301, мәйданы 520 кв.м., «торак пунктлар җирләре» | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Карадуган авылы, Себер тракты урамы, 51 нче йорт | 110,3 | Торак булмаган бина | 2021 елның I яртыеллыгы |